**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

26 октябрь 2023 ел № 3

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә ярашлы рәвештә, 2023 елның 24 октябрендә узган түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "Сез Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Ташкичү торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар, транспорт хезмәтләре сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 100 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 52 кеше катнашкан, бу 52% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 52 кеше тавыш бирде;

- «ЮК» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Шуңа нигезләнеп, гражданнар җыены түбәндәгеләрне карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында гражданнар җыены узган һәм аның нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

- Ташкичү торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар, транспорт хезмәтләре сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) - соравын кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб - адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев